



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ




# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ






РУЗАЛИЯ РӘХМӘТУЛЛА кызы
НИГЪМӘТУЛЛИНА
E-mail: nigmatullinarr@mail.ru

# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

“Без тарихта эзлебез” уку әсбабы Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча күпмәдәниятле белем бирү проекты кысаларында куллану өчен язылды һәм республика мәктәпләрендә сынау үтте. Уку әсбабына тарих, география, химия, биология, әдәбият, сәнгать буенча бөтендөнья, Россия, Татарстан тарихында бертөрле урын алган материаллар кертелде.




## УКУ ӘСБАБЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

- **поликультуралы** (күпмәдәниятле) **юнәлеш, ягъни эчтәлекне “культуралар диалогы” принцибында төзү;**
- **предмет монокультурасы кысаларыннан чыгу, максатлар төрлелеге булу;**
- **икенче телдә өйрәнелүче материалның уку һәм укыту программасы белән үзара бәйләнештә булуы.**

# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

## КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

**Безне планетабыз искиткеч зур, матур. Шул планетаның җыйнак кына бер өлешен тәшкил иткән Татарстанның башка беркайда да булмаган, кабатланмас үз матурлыгы, үз яме бар.**

**Гомумкешелек тарихы белән тыгыз бәйле Татарстанның да, һәр илнеке, һәр халыкныкы шикелле үк, үзенең бай тарихы, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге бар.**

**Бу китап сезне Татарстан республикасының кайбер төбәкләренә алып барыр, аның тарихындагы кайбер сәхифәләр белән таныштырыр.**

**Авторлар**



Без тарихта эзлебез


1 Татарстан җире — дуслык иле 4
2 Шагыйрьләрдә — халык җаны 8
3 Сөембикә рухы яши бездә 12
4 Монда синең Биләрең, монда синең Болгарың... 17
5 Изге җирләр 25
6 Бу — борынгы бабайларның туган-үскән җирләре 35
7 Һәйкәлләрдә — гасырлар авазы 47
8 Тарихларда шаулы эзе калган... 54
9 Ниләр калган безгә мираска?.. 60
10 Аягындагы читеген — болгар икән олтаны... 63
11 Табигый дәва чыганаклары 67


## УКУ ӘСБАБЫНЫҢ БҮЛЕКЛӘРЕ

1. Татарстан Республикасы символикасы
2. Халык шагыйрьләре
3. Данлыклы патшабикәләр
4. Җир йөзеннән юкка чыккан шәһәрләр
5. Изге урыннар
6. Меңъеллык шәһәрләр
7. Халык фетнәләре
8. Тарихи һәйкәлләр
9. Табигый һәйкәлләр
10. Табигый дәва чыганаклары
11. Халык иҗаты

I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СИМВОЛИКАСЫ












Татарстан җире — дуслык иле

**Татарстан дәүләтчелеге белән бәйле төп вакыйгалар**

**1920 нче елның 27 нче маенда** Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелде.

**1990 нчы елның 30 нчы августында** Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителде. 30 нчы август Татарстан халкының бәйрәме — Республика көне дип игълан ителде.

**1991 нче елның 12 нче июнендә** Татарстан халкы беренче Президентын сайлады.

**1991 нче елның 29 нчы ноябрендә** Татарстан Республикасының Дәүләт флагы кабул ителде.

**1992 нче елның 7 нче февралендә** Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кабул ителде.

**1992 нче елның 6 нчы ноябрендә** Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителде. Конституция татар һәм рус телләрен дәүләт телләре дип игълан итте.

**1993 нче елның 27 нче августында** Татарстан Республикасының Дәүләт гимны кабул ителде.

**1994 нче елның 15 нче февралендә** Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында дәүләтара мөнәсәбәтләрне билгеләүче Договор төзелде.

**2005 нче елның 30 нчы августында** халкыбыз Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итте.

**Татарстан Республикасының дәүләт символлары**

**Татарстан Республикасы Дәүләт флагы**

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы — яшел, ак һәм кызыл буйлы тукыма. Өске буе яшел, аскы буе кызыл, алар арасында флаг иңенең 1/15 өлешен тәшкил иткән ак буй. Бертигез яшел һәм кызыл буйлар һәрберсе флаг иңенең 1/7 өлешен тәшкил итә. Флагның иңе буена 1:2 чагыштырмасында.
Татарстан Республикасының Дәүләт флагында яшел төс — яз һәм яңарышны; ак — сафлыкны; кызыл төс житлеккәнлек, энергия, көч, тормышны аңлата. Бергәлектә бу төсләр Татарстанны якты ниятле, үзенең киләчәген бөтен яктан тәэмин итә алучы, яңарыштагы республика итеп гәүдәләндерә.
Татарстан Республикасы Дәүләт флагының авторы — рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов.

**Татарстан Республикасының Дәүләт гербы**

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы түгәрәк калкан рәвешендә.
Гербның уртасында — канатлы ак барс. Борынгы заманнарда барс уңдырышлылык алласы, балаларны яклаучы булып саналган. Татарстан гербында ул — республика гражданнарының, республика халкының яклаучысы. Барсның кызыл кояш җирлегендә сурәтләнүе — игелеклелек, уңыш, бәхет, тормыш билгесе. Барсның сул ягындагы түгәрәк калкан республикабыз гражданнарының хокукый, икътисади яктан һәм көч кулланудан яклангынлыгын



**Татарстанның беренче Президенты**

Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев республикабызны югары үсеш алган хокукый дәүләт, төрле милләт халыклары үзара тыныч һәм дус яшәгән республика итеп күзаллый. Һәм моның өчен бөтен көчен, тырышлыгын куеп хезмәт итә.

Ул 1937 нче елның 20 нче гыйнварында хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында гаиләдә тугызынчы бала булып дөньяга килә.

Абыйсына кадәр туган дүрт ир баланың дүртесе дә авырып үләләр. Шул сәбәпле әти-әнисе алардан соң туган ир балаларына сәламәтлек, ныклык, иминлек теләп торучы исемнәр куярга телиләр. Менә шулай Шәймиевләр гаиләсендә ике «тимер» малай — Хантимер һәм Минтимер үсә.

Башлангыч классларда Мин-

аларның чиста кырыйларын кисеп алып, дәфтәр ясыйлар. Газета кырыйларына, юллар арасына язалар. Ул елларда чын дәфтәрләр укучыларның һәм укытучыларның хыялында гына була.

Авыр вакытта укуына карамастан, мәктәп еллары турында Президентның күңелендә иң матур хатирәләр генә саклана. Үзендәге белемгә омтылу, тырышлык, түземлек кебек сыйфатларны ул нәкъ менә мәктәп тәрбияләде дип саный.

Кечкенәдән укырга ярата, һәр буш минутында кулына китап ала. Бигрәк тә Габдулла Тукай, Һади Такташ әсәрләрен яратып укый. Аларның бик күп шигырьләрен, поэмаларын яттан белә. Мәктәп китапханәсенә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» кайткач, аны елый-елый укыганын яхшы хәтерли. Шагыйрьнең язмышы, бу җыентыктагы шигырьләре аның өчен чын тетрәнү була. Президентыбыз хәзер дә яттан шигырьләр укырга ярата. Рус шагыйрь-

- **ТР дәүләтчелеге белән бәйле төп вакыйгалар**
- **ТР Дәүләт флагы. Дәүләт флагының авторы**
- **ТР Дәүләт гербы, авторы. Гербтагы сурәтләр, аларга аңлатма.**
- **ТР Дәүләт гимны. Дәүләт гимнының авторы**
- **ТР беренче Президенты – М.Ш.Шәймиев.**

Рузалия Нигъмәтуллина. 25.01.2021

# II ХАЛЫК ШАГЫЙРЬЛӘРЕ







- Поэзия – халыкның тарихы, уй-кичерешләре чагылышы
- Борынгы грек шагыйре Гомерның “Одиссея” һәм “Илиада” поэмалары
- Рус әдәбиятында “Игорь полкы турында җыр” поэмасы
- Болгар шагыйре Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы

# III ИДАРӘЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР



## Сөембикә рухы яши бездә

### Клеопатра

Исемнәре кешелек тарихына кереп калган хатын-кыз идарәчеләр күп түгел. Мисыр патшабикәсе Клеопатра — шуларның берсе.

Клеопатра безнең эрага кадәр 69—30 нчы елларда яши. Ул үз иленең, үз халкының бәйсезлеге өчен көрәшүче зирәк һәм үткен сәясәтче буларак танылa. Бик белемле була, күп телләрдә аралаша ала. Тарихчылар Клеопатраның яхшы психолог һәм оста әңгәмәдәш булуы турында язалар.


Клеопатра тәхеттә егерме ел чамасы утыра. Бу чорда Мисыр Рим империясеннән бәйсез булып яши. Дөрес, аның уенда Рим дәүләте белән Мисырны бергә кушу планы да була. Әмма бу план Рим идарәчесе, Клеопатраның ире, атаклы полководец Юлий Цезарь үтерелгәннән соң (безнең эрага кадәр 44 нче ел) юкка чыга. Клеопатраның Марк Антоний белән никахы да уңышсыз була. Рим императоры Октавиан Август көндәше Марк Антонийның гаскәрен тар-мар итә. Дошманына

12 Без тарихта эзлебез



СОРАУЛАР

1. Мисыр патшабикәсе Клеопатра нинди булган?
2. Рус патшабикәсе Екатерина Икенче нинди булган?
3. Россия тәхетендә утырганда, ул илнең үсеше өчен нәрсәләр эшләгән?
4. Сөембикә кайсы дәүләтнең ханбикәсе булган?
5. Ул кайчан һәм кайда туган?
6. Ни өчен Сөембикәгә Казан ханлыгы тәхетенә утырырга туры килгән?
7. Казан халкы Сөембикәне ни өчен яраткан, хөрмәт иткән?
8. Сөембикә турындагы риваять нәрсә турында сөйләнә?
9. Ә чынлыкта хәл ничек булган?
10. Сөембикә тормышының соңгы еллары турында тарихта нинди мәгълүматлар сакланган?




### Екатерина II

бик күп талантлы дәүләт эшлеклеләре, полководецлар, язучы, рәссам, музыкантлар үсеп чыга. Императрица үзе яхшы әңгәмәдәш була,

лары ачыла башлый, бик күп уку йортларына нигез салына. Ул хакимлек иткәндә Россиянең дөнья күләмендә абруе үсә.

**Исемнәре кешелек тарихына кереп калган, дәүләт белән идарә иткән хатын-кызлар: Мисыр патшабикәсе Клеопатра, Россия патшабикәсе Екатерина II, Казан ханбикәсе Сөембикә**

# IV ҖИР ЙӨЗЕННӘН ЮККА ЧЫККАН ШӘҺӘРЛӘР



Монда синең Биләрең,
монда синең Болгарың...

Кайчандыр зурлыгы, матурлыгы, бөеклеге белән бөтен дөньяга танылган, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында җимерелгән яки бөтенләй юкка чыккан шәһәрләр бар.

...1738 нче елда Саксония короле Август III үзенең яраткан кызы Мария Амалия Христинаны Сицилия корол... гә б...

килгәч, яшь королевага Неапольнең зиннәтле сарайларын, гүзәл паркларын күрсәтеп йөриләр. Искитәрлек әйберләр күп була бирелә. Әмма Мария Амалиянең тынычлыгын сарай залларында, парк аллеяларындагы борынгы статуялар ала. Каян килгән бу искиткеч матур сыннар? Карасаң, күптән түгел генә табылган икән алар. Ел ярым чамасы элегрәк Неапольгә якын гына атаклы Везувий вулканы тирәсеннән казып тапканнар. «Ә нигә казу эшләрен тавы итәгенә эшчеләр җибәрәләр.

Шахта 15 метр калынлыктагы лава катламын үтә. Бронзадан коелган ат сыны килеп чыга. Казуларны дәвам итәләр. Озак та үтми, ниндидер таш бина калдыклары янында язулы таш плитә табалар — «Theatrum Herculanense». Әйе, театр! Сәхнәсендә дистәләгән скульптура, атаклы кешеләрнең мәрмәр һәм бронза бюстлары аунап ята. Бу безнең эраның 79 нчы елында Везувий вулканы атканда

китапханә табалар. Антик чор галимнәренең китаплары (папирус төргәкләре), йөзләгән мәрмәр сын, йорт җиһазлары, стена фрескалары һәм әллә никадәр башка әйберләр... Тиздән табылдыклардан дөньяда тиңе булмаган музей оештыралар.

Король, якыннары белән киңәшеп, 79 нчы елда Везувий вулканы атканда, Геркуланум кебек үк юкка чыккан Помпеины казырга карар кыла.

*Помпеи* Рим империясенең иң матур шәһәрләреннән берсе булган. Аның үсеше безнең эрага кадәр IV гасырда ук башлана. Помпеиның чәчәк ату чоры ил белән император Август идарә иткәндә була. Һөнәрчелек һәм сәүдә ис-



... үсә. ... р архи- ..., урамнарга таш түшәлә. Шәһәр халкы, мохтаҗлык күрмичә, бай тормышта яши.

Һәм менә фаҗига: Везувий «уяна» да һич көтмәгәндә ата башлый. Күк йөзен тузан болыты каплый, яшен яшьни, күк күкри, һава түзеп тора алмас дәрәҗәдә кайнарлана. Халыкның бер өлеше шәһәрдән китеп өлгерә. Өлгермәүчеләр күбрәк була. Алар Помпеи белән бергә фаҗигале рәвештә һәлак булалар. Бер төн эчендә шәһәр 3—7 метр калынлыктагы көл астында кала.

Помпеида археологлар 1748 нче елда эшли башлыйлар. Хәзер ул җир астыннан тулысынча диярлек казып чыгарылган. Бүген бирегә дөньяның төрле якларыннан туристлар өзелми.



СҮЗЛЕК

**бөтенләй юкка чыккан** — совсем исчезнувший
**ел ярым чамасы элегрәк** — около полутора года назад
**казып чыгарган** — откопал
**тау итәге** — подножье горы
**лава катламын тишеп үтә** — проходит сквозь слой лавы
**бронзадан коелган** — отлитый из бронзы
**таш бина калдыклары** — останки каменного здания
**дистәләгән бюстлар аунап ята** — валяются десятки бюстов
**вулкан атылганда** — когда извергается вулкан
**мәрмәр корылма** — мраморная постройка
**чәчәк ату чоры** — эпоха расцвета
**таш түшәлә** — выкладывается камнем
**мохтаҗлык күрмичә** — не зная нужды
**түзеп тора алмаслык** — нестерпимо
**тулысынча диярлек** — почти полностью

**Борынгы Римдагы Геркуланум һәм Помпеи шәһәрләре.**
**Аларның юкка чыгу тарихы.**

# IV ҖИР ЙӨЗЕННӘН ЮККА ЧЫККАН ШӘҺӘРЛӘР



Биләр — Олуг шәһәр

Алексеевск районы Биләр авылы янында искиткеч зур шәһәр хәрабәләре ята. Балчыктан өелгән биек үрләр, тирән чокырлар — хәрби ныгытма эзләре — яшел чирәм белән капланган. Тигез басуда чүлмәк китекләре, сәер табылдыклар очрый. Күренеп тора: биредә кайчандыр тормыш гөрләгән.

Биләр Болгар дәүләтенең монгол яуларына кадәрге башкаласы булган. Аның даны бөтен дөньяга таралган. Шәһәрнең гомуми мәйданы 800 гектардан артып киткән. Биләр шикелле зур ган. Рус елъязмачылары аны Олуг шәһәр дип атаганнар. Шәһәр биек үрләр һәм стеналар белән әйләндереп алынган. Стена почмакларына нык манаралар утыртылган. Саклану корылмалары Биләрне ике өлешкә — эчке һәм тышкы шәһәргә бүлгән.

Эчке шәһәрдә Болгар ханы һәм аның якыннары, дәүләт белән идарә итүче кешеләр, дин башлыклары, бай сәүдәгәрләр һәм аларның хезмәтчеләре яшәгән. Шуңа күрә монда таштан, кирпечтән салынган матур биналар күп булган. Ныгытманың үзәгендә хан сарае.

Шәһри Болгар

Идел һәм Чулман буйларына кешеләр борынгы таш гасыры — палеолит чорында ук килеп төпләнгәннәр. Хәзерге шәһри Болгар территориясендә борынгы община строе чорында яшәгән кешеләрнең торак урыннары табылды. Монда яшәүчеләр якынтирәдәге халыклар белән генә түгел, ерак дәүләтләр белән дә сәүдә итешкәннәр. Археологик казу эшләре вакытында II—III гасырларга караган Рим акчалары табылу шул хакта сөйли.

IX гасыр ахыры — X гасыр башында шәһри Болгар әйләнәсендә ныгытма төзелә башлаган. Монда әмир һәм аның якыннары, танылган һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр яшәгән. Ныгытма Идел ярыннан башланган һәм ике канау бе-

**Татарстан территориясендәге Биләр (Алексеевский районы) һәм Шәһри Болгар (Спас районы) шәһәрләре**

Рузалия Нигъмәтуллина. 25.01.2021

**V**

# ИЗГЕ УРЫННАР





## ТАРИХ ҺӘМ ДИНИ ЙОЛАЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИЗГЕ УРЫННАР

**Израильдәге Изге чишмә, Мисырның Синай ярымутравында Изге Екатерина монастыре, Тибеттагы Юмбуланг монастыре.**
**Россиядә изге урыннарның берсе - Псков өлкәсендәге Псков-Печера Успение монастыре.**

Рузалия Нигъмәтуллина. 25.01.2021

# V ИЗГЕ УРЫННАР



## Кызыл чишмә

Түбән Кама шәһәренең читендә, Чулман елгасының текә яры астында, *Кызыл чишмә* (Красный ключ) исемле изге су чыганагы бар. Элек аны халык Изге чишмә дип йөрткән. Бүгенге исемен ул революциядән соң, 1921 нче елда алган.

Риваятьләргә караганда, XVII гасыр башында бу җирләргә болгар имамы Дәүхит килеп төпләнә. Ул тау итәгендә бер мәгарә казый. Бу мәгарә эченә үрмәләп кенә керергә мөмкин була. Имам мәгарә янына, ташны чокып, нәни генә бассейн да ясап


лый. Тарихчылар әйтүенчә, изге су алырга, изге суда коенырга дип, хәтта Персиядән дә килгәннәр. Юлчылар имамның тау башындагы кабер ташы янында дога кылганнар. Болгар имамы Дәүхитнең кабер ташы соңрак юкка чыккан.

Икенче бер риваять буенча, бу чишмәдән Изге Николай Чудотворец иконасын табып алалар. Шуннан бирле Изге чишмә мөселманнарның гына түгел, христианнарның да табыну урынына әйләнә. Гыйбадәт кылу өчен, тау башында кечкенә генә часовня салып куялар.


1882 нче елда бу җирләрне сәүдәгәр Стахеев сатып ала. Ул

ция, сууткәргеч, өйне су белән җылыту җайланмасы, Чулман ярына алып чыга торган җир асты юлы була. Йортның түбәсе һәм агачтан челтәрләп эшләнгән сокландыргыч бизәкле зур тәрәзәләре ерактан күренеп торган. Өйдәге каминнар төрле төстәге керамика белән бизәлгән, бүлмәләрдә кыйммәтле статуялар торган. Бу йорт 1900 нче елда төзелеп бетә. Йорт янында зур бакча, дүрт оранжерея, унбер теплица була. Биредә бик яхшы сортлы пальма, лавр һәм җимеш агачлары үсә. Җаен Стахеевлар кунакларын үзләрендә үскән шәфталу, лимон белән сыйлыйлар. Өстәлләрдә кыш буе яңа җыйган җиләк-җимеш, яшелчә, яңа









## Изге чишмә

Биләрдән төньяк-көнбатышка таба өч чакрым чамасы киткәч, куе урман башлана. Шул урман эчендә, Хуҗалар тавы итәгендәге *Изге чишмә* — табигатьнең гүзәл һәйкәлләреннән берсе. Халык аның мәңге бозылмый торган саф һәм шифалы суы тәнгә сәламәтлек

риваятьләр яши. Аксакалларның сөйләве буенча, биредә, тау башында, монгол яуларыннан яшеренеп яткан болгар кызларының хәрби ныгытмасы — «Кызлар каласы» булган, имеш. «Кырык кыз» каберлеге дә кайдадыр шушы тирәдә, имеш.

Бу чишмә Идел Болгарында IX—X гасырларда ук инде изге дип саналган, шуңа күрә аның янын-

өзелми. Мөселманнар чишмәгә, гадәттә, чәршәмбе көнне киләләр. Ни өчен дисезме? Чәршәмбе борыңгы болгар календаре буенча «кан көн» дип йөртелгән. Әле ислам дине кабул ителгәнгә кадәр, бу көнне Тәңрегә багышлап корбан чалганнар, мәҗүси бәйрәмнәр үткәргәннәр. Бу йола мөселман-татарлар арасында бүгенге көннәргә кадәр онытылма-

**ТАРИХ ҺӘМ ДИНИ ЙОЛАЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИЗГЕ УРЫННАР**

**Татарстан территориясендә Алексеевск районы Биләр авылы янындагы чишмә Яшел үзән районындагы Раифа монастыре, Түбән Кама шәһәре янындагы Кызыл чишмә изге санала.**

# МЕҢЪЕЛЛЫК ШӘҺӘРЛӘР





**Бу — борынгы бабайларның туган-үскән җирләре**

Җир шарында тарихлары мең елга якын булган яки мең елдан да арткан шәһәрләр бар. Рим һәм Краков — шундый шәһәрләрнең дөньяда иң танылганнары.

Тарихта *Краков шәһәре* турында беренче тапкыр 965 нче елда искә алына. Шәһәрнең иң зур үсеш алуы 1000 нче елга туры килә. Бу вакытта ул монахларның дини үзәге буларак танылa. 1038 нче елда король Казимир Краков шәһәрен дәүләт башкаласы итә. Шәһәр Польша корольләренең резиденциясе булып санала.

Краков бик борынгы һәм Европаның иң матур шәһәрләреннән санала. Ул ЮНЕСКОның дөньякүләм данлыклы тарихи һәйкәлләре исемлегенә кертелгән. Шәһәрдә Изге Войцех костёлы яки Анджей костёлы кебек Урта гасырда төзелгән биналар бик яхшы сакланган. Биредә Европаның иң борынгы югары уку йортларыннан саналучы Ягеллон университеты бар. Аңа 1364 нче елда нигез салынган.

*Рим* дөньяның иң матур шәһәрләреннән санала. Ул җиде калкулыкта урнашкан. 1871 нче елдан Рим — Италиянең башкаласы. Шәһәрдәге архитектура истәлекләре аның 3000 еллык тарихы булуын күрсәтә. Яңарыш чорында шәһәрне бизәүдә Рафаэль һәм Микеланджело кебек атаклы осталар эшләгән.

Рим шәһәрендә дөньяның иң кечкенә дәүләте — Ватикан урнашкан. Ватикан — католицизм дөньясы үзәге, Рим Папасының резиденциясе.

Россиядә дә меңьеллык шәһәрләр күп. Алар арасында Бөек Новгород, Ростов, Муром, Ладога кебек шәһәрләр рус елъязмаларында телгә алына.

*Ладога* — илебезнең иң төньягындагы иң борынгы рус шәһәре. 2003 нче елда ул үзенең 1250 еллыгын бәйрәм итте. Ладога Петербургтан 130 километр чамасы ераклыкта, Волхов елгасы буенда урнашкан. Ул, һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак, 750 нче елда барлыкка килә һәм төньяк славян кабиләләренең башкаласы булып санала. Борынгы рус кенәзләре династиясенә нигез салган, чыгышы буенча варяг саналган Рюрик Ладоганы үзенең резиденциясе итеп сайлый. Биредә хәзер дә йөз алтмышлап борынгы архитектура истәлеге саклана. Алар арасында кенәз Олег күмелгән сопка — биек курган, IX гасырда ук төзелә башлаган һәм биек башнялар белән ныгытылган таш стена — крепость



калдыклары, XII гасыр урталарында салынган һәм искиткеч матур фрескалар белән бизәлгән Изге Георгий чиркәве, Успение соборы, археологлар казып тапкан тагын да борынгырак таш корылма хәрабәләре бар. Борынгы крепость эчендә бик бай археология музее урнашкан. Бирегә ел саен меңнәрчә чит ил туристлары килә.


**СҮЗЛЕК**

**искә алына** — упоминается
**үсеш алуы** — развитие
**дини үзәк буларак** — как религиозный центр
**исемлеккә кертелә** — вносится в список
**калкулык** — возвышенность
**Яңарыш чоры** — эпоха Возрождения
**атаклы осталар** — знаменитые мастера
**чыгышы буенча** — по происхождению



Казан тарихын галимнәр XVIII гасырдан өйрәнәләр. Бу өлкәдә инде күп кенә ачышлар ясалган, калын-калын китаплар язылган. Шулай да «Казанга ничә яшь?» дигән сорауга бүген дә беркем дә төгәл генә җавап бирә алмый. Тарихчылар җавапны моңа кадәр бары тик язма чыганаклардан гына эзләгәннәр. Борынгы рус елъязмаларында Казан беренче тапкыр XIV гасыр ахырларында искә алына, димәк, ул шул чорда гына барлыкка килгән диючеләр булды. Икенчеләре Батый хан заманнарында ук төзелгән кала булырга тиеш дигән фикерне әйттеләр. Өченчеләре исә XVI гасырда язылган «Казан тарихы»ндагы 1177 нче елны нигез итеп алдылар. Ә бу исә шәһәргә 1000 түгел, ә нибары 800 яшь дигән сүз булыр иде.

1994 нче елда Казан Кремлен Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы дип игълан итү турында Татарстан Республикасы Президенты указы чыкты. Шул указ нигезендә музей-тыюлык Кремльне төзекләндерү һәм анда



**Польшадагы Краков, Италиядәге Рим, Россиядәге Ладога ШӘҺӘРЛӘРЕ**

.

# МЕҢЪЕЛЛЫК ШӘҺӘРЛӘР

## Алабуга

Алабуга — Татарстан Республикасының иң борынгы, иң кызыклы һәм бай тарихлы шәһәрләреннән берсе. Археологлар, XI—XIII гасырлардан башлап бүгенге көннәргә кадәр формалашкан җир катламнарын тикшереп, Алабуганың яшен ачыклый торган күп санлы әйберләр таптылар. Шәһәр Казанның яшьтәше булып чыкты: аларның икесенә дә XI гасыр башында, Идел Болгарында Ибраһим хан хакимлек иткәндә нигез салынган.

Хәзерге Алабуга шәһәре янында, Кама суында, элек судноллар бик еш баткан дип сөйлиләр. Халык моны җен, шайтаннар белән бәйләп аңлаткан. Шайтан, имеш, әнә теге биек тау башындагы манарада яшеренеп ята.


Кама елгасы төбендә бик зур үгезгә охшаган таш яткан. Болгар телендә үгез — «буга». Аңа «ала» («чуар») сүзен дә өстәгәннәр. Шулай итеп, борынгы калага «Алабуга» атамасын кушканнар.

Шәһәр исеменең килеп чыгышы турында башка фикерләр дә бар. Кайбер галимнәр «Алабуга»ны кеше исеме дип уйлый. Ә кайберләре якындагы күл балыгы исеменнән килеп чыккан дип саныйлар.

1780 нче елда Екатерина II указы белән Алабуга өяз шәһәре статусын ала. Бу вакытта Алабугада дүрт йөзләп йорт булып, анда меңгә якын кеше яшәгән.

Шәһәр үзәген Стахеев, Гирбасов, Ушков, Чернов һәм шул заманның иң бай башка сәүдәгәрләренең йортлары бизәгән. Аларның һәрберсе үзенчәлекле проект буенча салынган, шуңа күрә берсе икенчесен кабатламаган.

Кама буендагы химия заводларына нигез салучылар — шул чорның күренекле вәкилләре Ушковлар. *Пётр Капитонович Ушков* нигез салган Бондюг химия заво-







## Яр Чаллы

Татарстан Республикасының бүгенге географик картасын игътибар беләнрәк карасаң, нигезендә «Чаллы» атамасы яткан дистәдән артык торак пункты табарга мөмкин. Элегрәк, XIX гасырда, Казан губернасында утызлап Чаллы авылы булган. (Югары Чаллы, Түбән Чаллы, Тәберде Чаллысы, Казаклар Чаллысы...) Алар барысы да — татар авыллары. «Чал» — борынгы төрки сүз, «ак» дигән мәгънәне аңлата.

Яр Чаллы — Татарстанның Казаннан кала иң зур шәһәре. Анда 600 меңгә якын кеше яши. Бирендә эшләнеп чыга торган атаклы КамАЗ машиналары аркасында Чаллыны бөтен дөнья белә.

Чаллы — борынгы шәһәр. Озак еллар, хәтта гасырлар буена ул әллә ни зур булмаган торак пункты рәвешендә яшәп килде. Елга пристане һәм Кама яры буендагы ашлык саклау складлары, элеваторы белән танылды.

Шәһәргә кайчан нигез салынган соң? Бу сорауга җавап бирү бик авыр, чөнки архивларда язма документлар сакланмаган. Кайбер чыганакларга таянып, тарихчылар Чаллының барлыкка килү вакыты дип XVII гасырның беренче яртысын күрсәтәләр.

Чаллы территориясендә археологик казу эшләре бик аз күләмдә үткәрелгән. Шулай булуга карамастан кызыклы гына табылдыклар бар. Чаллының иң борынгы археологик истәлеге — хәзерге автовокзал тирәсендәге наратлыкта. Ул — безнең эрага кадәр II меңьеллыкта, ягъни моннан 3500 еллар элек яшәгән бура кабиләсе зираты. Татарларның борынгы бабалары бу якларга монгол яуларына кадәр килеп төпләнгәннәр. Хәзерге Элеватор тавында археологлар XII—XIII гасырларга караган савыт-саба ватыклары, пычак, орчыкбаш ише әйберләр таптылар. Әмма, Чаллының барлыкка килү вакытын билгеләү өчен, болар гына җитәрлек түгел, казу эшләрен дәвам итәргә кирәк.

Тарихи чыганаклар Чулман ярларына килеп төпләнгән борынгы кешеләрнең игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнүләре турында сөйли. Моның сәбәбе гади: тирә-юньдә уңдырышлы басулар, мал-туар асрау өчен, хуш исле печән бирә торган тугайлар, болыннар булган.

XIX гасырда Чаллы игенчеләре



**Казан, Алабуга, Яр Чаллы – республиканың иң борынгы, иң бай тарихлы шәһәрләре.**

# ХАЛЫК ФЕТНӘЛӘРЕ





Пугачёв житәкләгән крестьян сугышлары аерым урын алып тора. Пугачёв фетнәсе 1773 нче елның көзендә, Екатерина II патшалык иткән заманда күтәрелә. Урал — Идел буйларында яшәгән крестьяннар: руслар, татарлар, башкорт, мари, удмуртлар, төркем-төркем булып, Пугачёв армиясенә

## Тарихларда шаулы эзе калган...

Кешелек тарихында бер сыйныфның (коллар, ярлы крестьяннар, эшчеләрнең) үзләрен изүче икенче сыйныфка каршы көрәше турындагы фактлар бихисап күп. Безнең эрага кадәр 73—71 нче елларда Италиядә Спартак җитәкчелегендәге коллар восстаниесе, 1358 нче елда Франциядәге Жакерия восстаниесе, 1381 нче елда Англиядәге Уот Тайлер восстаниесе, 1524—1525 елларда Германияне чолгап алган Бөек крестьяннар сугышы турында сезнең инде укыганыгыз бардыр.

Россиядә дә гади халык гаделлек өчен көрәшкә күп тапкырлар

Степан Разин, Емельян Пугачёв фетнәләре була.

*Степан Разин* җитәкчелегендәге фетнә 1670—1671 нче елларда Россиянең көньяк өлкәләрендә була. Ул кыска вакыт эчендә Дон, Идел буйларын чолгап ала. Восстаниедә катнашучы казаклар һәм крестьяннар арасында руслар, татарлар, чуваш, мари, мордвалар һәм башка милләт кешеләре була. Разинчылар патшага хезмәт итәргә, ә боярларны, дворяннарны, сәүдәгәр һәм воеводаларны «кыйнарга» чакыралар.

Фетнәчеләр Царицын (хәзерге Волгоград), Әстерхан, Сарытау, Саранск, Пенза, Сембер (Ульяновск) шәһәрләрен алалар. Аларга Тамбов, Түбән Новгород өязләреннән дә крестьяннар ку-







## Минзәлә пугачёвчылары

Күп галимнәр Минзәлә шәһәренең исеме гарәпчәдән алынган дигән фикердә торалар. «Мәнзәл» сүзе элекке заманнарда «сәяхәтчеләрнең туктап ял итү урыны» дигән мәгънәне аңлаткан. Археологларның Ык буенда тапкан әйберләре борынгы кешеләр монда йөз мең еллар элек үк яшәгәннәр дип фаразларга мөмкинлек бирә. Бу җирләрдә элек-электән төрле милләт кешеләре: татар, башкорт, рус, чуваш, мари, удмурт, мордвалар яшәгән.

Минзәлә өязе XVIII гасыр ба-

гаскәрләрен куып җибәрергә чакыра, алпавыт һәм чиновникларның байлыкларын талап бүлешергә рөхсәт бирә. Манифест крестьяннарның күңеленә бик хуш килә. Инде октябрь ахырларында Минзәлә тирәсендә беренче Пугачёв отрядлары оеша. Юшады, Исәнгол, Әхмәт, Сарсаз, Үрмәт авылы крестьяннары күршедәге алпавыт утарларына һөҗүм итәләр, талыйлар.

Пугачёв Җаек буенда башланган фетнәне Чулман буена да таратырга гына түгел, ә аның белән идарә итәргә дә кирәклеген яхшы аңлый. Шуңа күрә Минзәлә өязенә үзенең шәхси эмиссарын — Уфа өязе Бөрҗән волостеның йөзбашы

лар. Атышлар көн буе дәвам итә. Икенче көнне ике якта да тынлык урнаша. 25 нче декабрьдә фетнәчеләр яңадан ут ачалар. 26 нчы декабрьдә 1500 кешелек фетнәчеләр отряды патша гаскәрләренә һөҗүм итә, крепостьны штурмлау башлана. Ләкин гарнизондагы хәрбиләр, Минзәлә елгасындагы буаны җибәреп, фетнәчеләргә юлны ябалар. Крестьяннар крепостька икенче яктан һөҗүм итеп карыйлар. Тик бирегә аларны капитан Алексеев отряды каршылый. Каты сугышлардан соң фетнәчеләр крепость тирәсендәге бистәгә бәреп керәләр. Берничә йорт һәм амбарга ут төртәләр, алты солдатны

манифест крестьяннарны патша

крепостьны утка тота башлый-

гып һөҗүм ясыйлар. Крестьяннар



...масында, алты агач баш... Дүрт башня һәрьяктан ...ике башняның капкалары ...постьның стеналары нарат ...рдән ике кат итеп салын... стена арасына вак таш ...ан. Стеналарның калынлы-

Пугачёв отрядлары Зәйгә якынлашканда, крепостьны саклаучыларда тирә-яктагы хәл турында бернинди дә рәсми мәгълүмат булмый. Ә халык арасында төрле сүзләр йөри. Имеш, тирә-яктагы бөтен авыллар да инде пугачёв-



...метрдан ... биеклере ...рга җитә. ...стька башкортлар, ну... ...уп тапкырлар һөҗүм итә... ...ндый һөҗүмнәрен бер... ...епость яндырыла.

## КЕШЕЛЕК ТАРИХЫНДА АЗАТЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШ

**Италиядәге, Франциядәге, Англиядәге, Германиядәге крестьяннар чыгышлары.**
**XVI гасырда Россиядә Степан Разин, Пугачёв җитәкчелегендәге фетнәләр.**
**Минзәлә крепосте. Минзәләдә Пугачёв отрядлары төзелү.**
**Зәй крепосте. Пугачев отрядларының Зәйгә керүе. Сәнәкчеләр фетнәсе.**

# ТАРИХИ ҺӘЙКӘЛЛӘР




## Һәйкәлләрдә — гасырлар авазы

Борынгы шәһәрләр, гадәттә, ике өлештән торган. Шәһәр үзәгендә, аның иң борынгы өлешендә, кагыйдә буларак биек тау башында, ныгытылган крепость калкып торган. Ә аның тирәягында һөнәрчелек бистәләре урнашкан. Шәһәрнең ныгытылган үзәгендә кенәз (хан, король) резиденциясе, дәүләт учреждениеләре, гыйбадәтханәләр урнашкан булган.


Чехиянең башкаласы Прага дөньядагы иң матур шәһәрләр исемлегенә керә.

Аңа IX гасыр ахырларында нигез салынган, язма чыганакларда ул 880 нче елдан ук телгә алына башлый. *Прага кремле* (Пражский град) Эльба елгасына коя торган Влтаваның сулъяк ярындагы биек калкулыкта урнашкан. XIV гасырда, Чехиядә король Карл IV хакимлек иткән чорда, Влтаваның ике як ярын тоташтыручы гаҗәеп зур һәм матур күпер төзелә («Карл күпере» бүгенге көнгә кадәр сакланган) һәм әле дә эшләп килүче атаклы университет ачыла.

Прага кремленең үзәк өлешен король сарае билән тора. Шул тирәдә генә 920 нче елларда изге Георгий (Иржи) чиркәвенә һәм бүгенге көндә Чехиянең төп храмы саналучы









изге Вита соборына нигез салына. Прага кремлендә чех дәүләтенә нигез салучы атаклы кенәз Вацлав яшәгән. Ул 935—936 нчы еллар тирәсендә үлгән һәм изге Вита соборында күмелгән. Шуны да әйтергә кирәк: Казан Кремлендә табылган чех акчасы Вацлав хакимлек иткән чорда сугылган. Прага кремлендә Чехия тарихының соңгырак чорларына караган башка архитектура истәлекләре дә күп. Хәзер биредә, борынгы традицияне дәвам итеп, Чехия Республикасы президентының резиденциясе урнашкан.

Россиянең башкаласы Мәскәү борынгы елъязмаларда беренче тапкыр 1147 нче елда телгә алына. 1156 нчы елда хәзерге *Мәскәү Кремле* территориясендә беренче хәрби ныгытмалар төзелә башлый. Ныгытмаларның озынлыгы 850 метр, ә тулаем мәйданы 3 гектарга якын була. 1238 нче елда монгол яулары вакытында Кремль җимерелә. Әмма аны яңадан торгызалар. 1264 нче елдан Кремль Мәскәү кенәзләренең резиденциясе була. 1485—1495 нче елларда ул яңабаштан торгызыла. Кремльне торгызуда Италиядән махсус чакыртып китерелгән осталар катнаша. 1812 нче елда, Мәскәүгә Наполеон армиясе кергәннән соң, күп кенә тарихи һәйкәлләр янгында юкка чыга. Чигенгән вакытта, Наполеон Кремльне шартлатырга боера. Тик, бәхеткә каршы, ул боерык үтәлмичә кала. Кремльнең күп кенә корылмаларын, ярым җимерек башняларын яңадан торгызуга ике дистә ел кирәк була.

Кремль стеналары буйлап төзелгән башнялар саны егермегә җитә. Иң биеге — 80 метрлы Троицк башнясы.

1990 нчы елдан Кремль ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы һәйкәлләре исемлегенә кертелгән. 1995 нче елдан Кремль ачык һавадагы музей буларак хезмәт итә башлый.

### СҮЗЛЕК

**Эльба елгасына коя торган** — впадающая в реку Эльба

**махсус чакыртып китертелгән** — специально приглашённый

**чигенгән вакытта** — когда отступали

**шартлатырга боера** — приказывает взорвать

**боерык үтәлмичә кала** — приказ остаётся невыполненным

**ярым җимерек** — полуразрушенный

**ачык һавадагы музей** — музей под открытым небом

**бөтендөнья мирасы** — всемирное наследие

**Чехиянең Прага кремле, Мәскәү Кремле, Казан Кремле - ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы һәйкәлләре исемлегендә.**

Рузалия Нигъмәтуллина. 25.01.2021

# VII ТАРИХИ ҺӘЙКӘЛЛӘР


## Казан Кремле



Башкаланың архитектура үзенчәлеген, халыкның милли рухын саклый торган тарихи, изге урыннарның берсе — Казан Кремле, борынгы Ак кирмән.

Казан Кремле бербөтен архитектура ансамбле буларак формалашкан. Ул моннан мең еллар элек үк бүрәнә стена белән әйләндереп алынган булган. XII гасыр ахырында аны биек таш стена алыштыра. Хәзерге көнгә кадәр сакланган Кремль стеналары исә XVI гасырның икенче яртысында төзелгән. Бу стенада ату җайланмалары һәм гөмбәзле 13 башня була.

Җиде катлы, 58 метр биеклектәге Сөембикә манарасы — Кремльдәге иң изге, иң истәлекле корылма. Ул — дөньяда сирәк очрый торган авыш манараларның берсе. Аның авышлыгы 1,9 метр. 1918—1935 нче елларда манара очында торган алтынсу ярымай 1991 нче елда яңадан куелды.



Кайбер тарихчылар Сөембикә манарасын Казан ханлыгы чорыннан калган бердәнбер архитектура истәлеге дип саныйлар. Икенчеләре аны рус һәм татар осталары тарафыннан XVII йөзнең икенче яртысы — XVIII йөзнең башында салынган дип исәпли.

XVI гасырның беренче яртысында бу урында Хан мәчете булган.

Урта гасырдагы Кремльдә матурлыгы белән шаккатырырлык биналар күп булган. Морзаларның, байларның ике катлы таш йортлары Шәрекъ бизәкләре белән аерылып торган. Безнең чорга Хан сарае, хөкем йорты, искиткеч матур төрбәләр (мавзолейлар) һәм мәһабәт манаралы мәчетләрнең исемнәре генә килеп җиткән.

Кирпечтән салынган һәм искиткеч матур итеп бизәлгән, суүткәргеч, канализация торбалары

## «Шайтан каласы» — Ак мәчет



Алабуга тарихында әлегә кадәр ачылмаган серләр күп. Шундый серләрнең берсе — шәһәрнең көньяк-көнбатыш читендә, 60 метр биеклектәге тау башында атаклы *Шайтан каласы*. Күп гасырлык шәһәр тарихының төп шаһитын — таштан салынган бу манараны руслар шулай атый. Татарлар Ак мәчет диләр. Бирегә борынгы Алабуга шәһәрлеге





булган. Ныгытмалары да бар: туфрактан өелгән өч рәт үр һәм тирән канаулар. Өч йөз ел буена галимнәрне кызыксындырып килгән бу шәһәрлекнең хәзерге Алабуга тарихы белән тыгыз бәйләнеше соңгы елларда үткәрелгән археологик тикшеренүләрдән соң ачыкланды.

1993 нче елда күренекле археолог А. Х. Халиков Алабуга шәһәрлегендә киң казу эшләре үткәргән. Нәтиҗәдә җир астында бер таш бина хәрабәләре ачылган. Бинаның нигезе яхшы сакланган: һәрьяк стенасының



**Алабугадагы “Шайтан каласы” – Ак мәчет, аның тарихы.**

# IX ТАБИГЫЙ ҺӘЙКӘЛЛӘР







## Нилəр калган безгə мираска?..

Җир шарында кеше кулы белән түгел, ә табигать үзе ясаган һәйкәлләр күп. Алар кешелек тарихының серләрен бүгенгә кадәр саклыйлар.

125 ел дәверендә галимнәр Европада өч йөзгә якын борынгы мәгарә тапканнар. Әлеге мәгарәләрнең стеналарында палеолит чоры сурәтләре сакланып калган.

*Альтамира мәгарәсе* Испаниянең Сантильяна дель Мар шәһәреннән ике километр ераклыкта. Бу мәгарә уникаль тарихи һәйкәл булып санала, чөнки аның стеналарында борынгы кешеләр ясаган рәсемнәр сакланган. Мәгарәне 1879 нчы елда археолог Марселино Санс де Саутуолой ача. Андагы рәсемнәргә 14 мең ел дип исәпләнә. Борынгы кешеләр, ауга чыгар алдыннан, йола буенча үсеп, боз кристаллары зураялар.

Альтамира мәгарәсенең заллары 280 метрга сузыла. Кайчандыр туристлар өчен Альтамирада экскурсияләр үткәргәннәр. Ләкин экскурсияләр вакытында стеналардагы рәсемнәргә зыян килә башлаган. Шуңа күрә туристлар өчен мәгарәнең копиясе ясала. Ул 2001 нче елның 17 нче июлендә ачыла, һәм анда беренче керүчеләр Испания короле белән королева була.

Альтамира ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән.

Уралдагы *Көнгер Боз мәгарәсе* — гаҗәеп табигать һәйкәле. Мәгарәнең бормалы юллары һәм заллары алты мең метрга җитә. Көнгер Боз мәгарәсе дөньяда гипслы мәгарәләр арасында озынлыгы буенча алтынчы урында тора, ә матурлыгы белән, мөгаен, беренче урындадыр.


Табигать, искиткеч матур бизәкле заллар ясар өчен, мең еллар буена үсеп, боз кристаллары зураялар. Стеналар һәм түшәмнәр төрле формадагы челтәрле бизәкләр белән каплана.

Көнгер Боз мәгарәсенә 10—12 мең ел. Аның эчендә тагын егерме мәгарә, алтмыш күл бар. «Көнгер» сүзе татарча «коңгырт» сүзеннән үзгәртелгән, «кара кучкыл» (смуглый) дигән мәгънәне аңлата.

Мәгарәдә беренче тикшеренүләр XVIII гасырда башлана. Хәзер Боз мәгарәсе Бөтенроссия күләмендәге табигать һәйкәле буларак билгеле. XX гасыр башыннан ул экскурсияләр өчен җайлаштырылган.

СҮЗЛЕК

**мәгарә** — пещера
**ауга чыгар алдыннан** — перед тем как идти на охоту
**йола буенча** — по обычаю
**сурәт** — изображение
**төрле тамгалар куйганнар** — ставили







## Кама Тамагы мәгарәләре

Урта Иделдәге Кама Тамагы җирләре аша элек Көнчыгыш белән Көнбатышны, Көньяк белән Төньякны тоташтырган зур сәүдә юлы узган.

Кешеләр бу тирәләргә бик күптәннән килеп урнашканнар. Археологик казу эшләре вакытында, монда борынгы кешеләр яшәгән урыннар табылган. Бу җирләрдә монгол явына кадәр болгарлар яшәгәннәр. Бүгенге Богдашкино авылы янында элек Ашлы шәһәре булган. Халык игенчелек, умартачылык, бакчачылык, бурлакчылык белән шөгыльләнгән.

Кама Тамагы турында беренче тарихи мәгълүматлар XVII гасыр елъязмаларында бирелә. Ул башта Богородское исемле кечкенә генә балыкчылар посёлогы булган, ә инде гасыр уртасында зур сәүдә һәм җир эшкәртү үзәгенә әверелгән. 1939 нчы елдан Кама Тамагы шәһәр статусын ала.

Борынгыдан бу җирләрне «Тау ягы» дип йөрткәннәр. Мондагы таулар йөзләрчә километрларга җитә һәм күп санлы мәгарәләре белән дан тота. Лобач тавы, Юрьев мәгарәсе, гипс рудникгы кебек урыннар әле бүген дә яхшылап өйрәнелмәгән. Табигать һәйкәлләре булып саналган Карамал күле (Байкүл), Урман күле, Теньки даласы, Лабыч тавы дәүләт саклавы астында.

Лабыч тавы Идел калкулыгының дәвамы булып тора. Тауның мәйданы якынча 240 гектар. Бөек рус художнигы Илья Репин үзенең «Иделдә бурлаклар» дигән картинасын нәкъ менә шушы тау өстеннән язган.

Бик кызыклы тау куышларының берсе — Иделнең уңъяк ярындагы Юрьев тауларында. Аны халык электән *Юрьев мәгарәсе* дип атый. Мәгарәгә керү урыны — 30 метр тирәнлектә. Мәгарәнең заллары һәм коридорлары күп. Коридор түшәмнәре сары һәм күксел доломит плитә, ә стеналары гипс. Гипс урыны белән ачык төстән караңгы төскә, ә урыны белән ак һәм алсу-күк төскә күчә. Мәгарәнең идәне һәм түшәме төсле доломит кисәкләреннән тора. Стеналарында һәм түшәмнәрендә кальцит токымнары күренә.

Идел елгасы буйлап түбәнгә табарак тагын бер гаҗәеп гүзәл урын бар: бу — *Сөйке таулары.* Казаннан 110 километрдагы әлеге таулар унбер километрга сузыла. Сөйке таулары моннан 250 миллион ел элек ясала башлаган. Моны соры, ачык соры доломит, сары, коңгырт известьташ, ак һәм соры гипс ятмалары ачык күрсәтә.

Сөйке таулары Соколёнок таулары яныннан башланып китә. Узган гасырда бу тауларның башланган урынын табигать үзе билгеләгән. Бу урында ярда ун метр озынлыктагы Кирель ташы яткан. Аны «хәтәр таш» яки «һәлакәт ташы» дип йөрткәннәр. Бу таш кайчандыр биек таудан аска килеп төшкән. Язгы ташу вакытында ул көчле агым белән Идел фарватерына килеп яткан, һәм суднолар өчен бик куркыныч хәл тудырган. Елганың бу урынындагы көчле агым судноларны ташка таба

**Испаниядәге Альтамира мәгарәсе.**

**Россиядә Пермь өлкәсендәге Көнгер Боз мәгарәсе.**

**Татарстанның Кама Тамагындагы мәгарәләр, аларның үзенчәлекләре.**

# X ТАБИГЫЙ ДӘВА ЧЫГАНАКЛАРЫ



Яловодагы табигый чыганакларның кирәклеген һәм әһәмиятен яхшы аңлап, Византиянең башка императорлары да төзекләндерү эшләрен дәвам итәләр.

Госманлы империясе чорында, әнисе ревматизм авыруыннан терелгәч, солтан Габделмәҗит монда яңа мунчалар һәм сарайлар төзетә, яхшы юллар салдыра.

Беренче бөтендөнья сугышы (1914—1918), 1919—1920 нче еллардагы сугыш һәм Балкан сугышы (1921—1923) вакытында данлыклы кайнар су чыганаклары онытылып тора. Мондагы биналар, мунчалар, сарайлар, җимерелеп, ташландык хәлгә килә.

Төркия президенты Мустафа Кемаль Яловога беренче тапкыр 1929 нчы

Табигый дәва чыганаклары

Кеше,— үләннәр, агачлар, хайваннар кебек үк, табигатьнең бер өлеше. Шуңа күрә табигатьтә кеше сәламәтлеген ныгыта һәм авыруларны дәвалый торган урыннар, табигый чыганаклар күп.

Моннан йөз еллар элек Чехословакиянең Падебрады дип аталган урынында углекислый газлы, магнийлы, кальцийлы, күкертле-водородлы минераль суларга бай чыганаклар ачканнар. Тикшергәннән соң, барысы 13 төрле минераль чыганак булуы ачыкланган. Аларның шифасы курорт ачарга сәбәпче булган.

*Падебрады курорты.* Прага

*рорты.* Ул Истанбул шәһәреннән 120 километрда, биек таулар арасында. Мәгарәләр, калын урманнар бу җирләргә ниндидер әкияти серлелек бирә.

Тау-таш арасыннан агып чыккан кайнар минераль суның составында натрий хлориды, кальций сульфаты, фторидлар бар. Җир астыннан чыкканда, суның

суында яланаяк басып торсаң, аяктагы җәрәхәтләр бик тиз төзәлә, мәгарәләрдән, таш араларыннан чыккан кайнар парны сулау аллергия, сулыш юллары авыруларыннан яхшы дәвалый.

Яловодагы кайнар минераль суның шифасын кешеләр борынгы заманнарда ук белгәннәр. Император Константин I бик озак

«Шифалы су» санаторие

Үзенең минераль сулары белән Татарстанда гына түгел, бөтен илдә билгеле «Шифалы су» санаторие Татарстанның Менделеев районындагы Ижевка авылы янында. Чулман елгасының биек ярында, табигатьнең искиткеч матур

сыр урталарында Ижевка авылы янында, җир астыннан тозлы су чыгып, күл барлыкка килә. Кешеләр хайваннарның шушы күлгә җыелып су эчүләренә игътибар итәләр. Тиздән халык арасында бу суның дәвалау үзенчәлеге турында хәбәр тарала. Күл янына, авыруларыннан котылырга теләп, төрле җирләрдән кешеләр килә башлый. Халык чыганакны «тере су» дип атый. Алабуга табибы Н. Г. Крылов 1876 нчы елда Ижевка суының шифасы турында Санкт-Петербургка

бик зур була. Күп еллар буе ашказаны авыруыннан интегеп, шушы суны эчеп терелгәч, ул шифалы чыганакны бөтен илгә танытуны үзенә максат итеп куя. Революциягә кадәр бу җирләр отставкадагы генерал В. К. Павловскийның дачасы була. Генерал күбрәк Санкт-Петербургтагы йортында яши, ә биредә ял итәргә, ауга йөрергә генә кайта. Д. Ф. Спиридонов су чыга торган урынны арендага ала. 1903—1910 нчы елларда ул сихәтле суны өйрәнә һәм шифаханә ачар-

һәм сәламәтләндерә
ык турындагы хәбәр
бөтен тирә-юньгә та-
ыруларыннан терелү
әр шушы урынга килә
. Сазлыктагы ләмнең
дәвалау үзенчәлеге
гаҗәпләндергән һәм
аятьләр туурга сәбәпче
әлән, авыл картлары
кытта Бәкер сазлыгы-
псымлы ат көтүе төшә
нар. Имештер, атлар
әм сәламәтләндерүче
лар, шифалы Бәкер
суын эчәләр дә, сәла-
м көч җыеп, яңадан
үтәреләләр икән...
бу — матур риваять
кта исә хәл башка-
Озак еллар буе та-
шләгән М. И. Игнатьев
ә игътибар итә: шушы
яшәүчеләр, Бәкер

**Сәламәтлекне ныгытучы һәм авыруларны дәвауччы табигый чыганаклар**

Чехословакиянең Падебрады курорты. Төркиянең Ялово-Термаль курорты.

Татарстанда **“Бәкер”** (Лениногорск районы), **“Шифалы су”** (Менделеевск районы) санаторийлары. Аларда төп дәвалау чыганаклары: күкертле-водородлы ләм һәм берничә төрле минераль су.

# XI ХАЛЫК ИҖАТЫ



Арча читекләре

Күн итекләрнең тарихы да күптәннән башлана. Күн итекләр борынгы сугышчыларның аякларын салкыннан да, юештән дә, төрле җәрәхәтләрдән дә саклаган. Яраланган яки озак йөрүдән җәрәхәтләнгән аяклардан саркыган кан күренмәсен өчен, беренче күн итекләр кызыл төстә булган. Мондый итекләр бик кыйммәт торган һәм аларны бай сугышчылар гына кигән.

Тире эшкәртү серләрен болгарлар яхшы белгәннәр. Алар теккән күн читекләрнең бәясе дөньяның иң зур базарларында бик кыйммәт булган. Бөек Болгар дәүләтендә яхшы сыйфатлы йомшак күннән тегелгән итекләрне байлар гына түгел, гади сугышчылар да, гади халык та кигән. Хатын-кызлар, балалар өчен читекләрне йомшаграк һәм матуррак итеп эшләгәннәр.

Ханнар, морзаларның гаиләләре өчен читекләрне төрле төсләрдәге чигүле күннән теккәннәр. Чигүле читек тегү серләре болгар чорыннан безнең көннәргә кадәр буыннан-буынга тапшырылып килеп җиткән. Биектауда, Арчада тегелгән милли аяк киемнәренә дөнья базарында бүген дә тиңлә[р]де ук булган дип саныйлар. Борынгы Арча Казансу елгасының биек ярында таш стена белән әйләндереп алынган крепость булган. 1552 нче елда, Казан ханлыгына һөҗүм иткәндә, Иван Грозный Арчаны яндыра. 1606 нчы елдан Арча рус крепосте булып санала башлый. 1781 нче елда өяз шәһәре статусын ала.

Арча милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе күн читекләр, башмаклар, бәрхет туфлиләр тегә. Бизәкле аяк киеме җитештерү техникасы гаять катлаулы. Элек-электән аяк киеменең үзенчәлекле бизәкләренә кешене саклау — магия мәгънәсе бирелгән. Бизәкләр нигезендә — үсемлек һәм җәнлек мотивлары. Алар арасында болыт сыман, лотос сыман сурәтләр, лалә чәчәге сурәте киң таралган. Читек бизәкләре мөгез, песи башы, йөрәк формасындагы сурәтләр булу белән аерылып тора. Читекнең өске өлешендәге дулкын мотивы суны символлаштыра.

Күн мозаикасы стилендә тегелгән башмакларны төсле тукымадан, күн кисәкләреннән аппликация ясап бизиләр һәм декоратив шнурлар, сәйлән, мулине җебе белән матурлыйлар.

Бизәкләп эшләнгән читекләр татар халкының милли киеменең



Аягындагы читегең – болгар икән олтаны...



Кукмара итекләре

Киез итекләрне безнең эрага кадәр IV гасырда Урта Азиядә уйлап тапканнар. Бу аяк киеме тауларда, далаларрынгыдан дәвалау чарасы булып саналган. Ә сарык йонынннан басылган киез, дымны яхшы йотса да, үзе коры калуы белән файдалы булган. Рус патшалары Пётр I һәм Екатерина II дә мондый итекләрне бик яратып кигәннәр.

Комаровлар сәүдә йорты» буларак оеша. Бертуган Николай һәм Сергей Комаровларның җыйнак кына остаханәләре ишегалдында була. Монда басылган киез итекләргә сорау көннән-көн

бар. Себер халыкларының унтасы, татар читекләре, русларның киез итекләре бөтен дөньяда билгеле. Бу аяк киемнәрен гади халык та, патшалар, ханнар да бик яратып һәм теләп кигәннәр.

СҮЗЛЕК

**үткен тешләр** — острые зубы
**җәрәхәт** — рана
**тире** — шкура, кожа
**табигый шартлар** — природные условия
**тәэсир иткән** — повлияло
**тигезлекләр** — равнины
**агач кайрысы** — древесная кора
**сыгылмалы** — гибкий
**сыналган аяк киеме** — испытанная обувь

## АЯГЫҢДАГЫ ЧИТЕГЕҢ – БОЛГАР ИКӘН ОЛТАНЫ...

**Италиядә, борынгы Римда тегелгән аяк киемнәре.**
**Россиядә беренче киез итек басу үзәкләре – Ярославль, Түбән Новгород өлкәләре.**
**Бөек Болгар дәүләтендә күн эшкәртү тарихы. Беренче күн итекләр.**
**Арча милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе.**
**Кукмара киез итек фабрикасы. Татар күн аяк киеменең үзенчәлеге.**

Рузалия Нигъмәтуллина. 25.01.2021

# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ



Дөньякүләм тарихи вакыйгалар, исемнәре тарихка кереп калган күренекле шәхесләр, әһәмиятле фәнни ачышлар һәм археологик табышлар, дөнья әдәбиятында урын алган әсәрләр, табигый байлыклар – боларның барысы да Татарстанның тарихында, яшәешендә дә урын алган.

Димәк, Татарстаныбыз -Россиянең генә түгел, ә бөтен җир шарының гасырлар буенча яшәп килгән тулы хокуклы энҗе бөртеге.




# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ...

Шушы яктан, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы якта безнең эзләр калсын,
Мирас булып килер яшьләргә.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шул туфракта язсын яшәргә.

Клара Булатова




Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен;
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара!

Мөдәррис Әгъләмов.

